# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге составына керүче Иске Мочалкино торак пунктында 2023 елга үзарасалым кертү турында

№ 1 18 октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясынигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Иске Мочалкино торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Иске Мочакино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 5000 сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
- Иске Мочалкино торак пунктындагы чишмәне ремонтлау (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- Иске Мочалкино торак пунктында Овражная урамына юллар ремонтлау (сатып алу, вак таш,ком җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Иске Мочалкино торак пунктында янгын гидранты комплектлау ( янгын колонкасы, җиңсә, металл шкаф сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Мочалкино торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Иске Мочалкино торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (махсус җиһазлар лампалары сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Шәдче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.В.Шрыков